| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Баулы шәһәре № 262

Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

18 статьяның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«район бюджеты акчаларының бердәм счетыннан күчерелгән акчалар һәм район бюджеты акчаларының бердәм счетына күчерелгән акчалар арасындагы аерма, район бюджеты акчаларының бердәм счетында калдыклар белән идарә итү буенча операцияләр үткәргәндә.

18 статьяның 16 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

абзац 2 пункта 2 статьи 48 изложить в следующей редакции:

48 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы финанс елының соңгы эш көненә кадәр район бюджеты үтәлешенә казначылык хезмәте күрсәтүче орган билгеләнгән тәртиптә район бюджетының бердәм счетында калган акчалар чикләрендә бюджет йөкләмәләрен түләргә тиеш.».

2. Әлеге карарны www:pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм www:Bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында закон белән билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин